Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

, Республика Татарстан, Сабинский район
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Килдебәк авылы,
Кооператив урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.01.2026

КАРАР
№1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннарын булдыру турында

РФ Хөкүмәтенең “Яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урыннан-урынга күчерү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китереүе мөмкин булган өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында” 28.12.2020 елгы №2314 карарының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннары булдырырга, шул исәптән мондый туплау урыннарын оештыру күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракларда, түбәндәге адрес буенча:

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Килдебәк авылы, Кооператив ур., 20а, Килдебәк авыл җирлегенең административ бинасы, янәшә урнашкан 23 нче каб. бинасы.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны җирлекнең рәсми сайтында, җирлекнең түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә: ТР, Саба районы, Килдебәк авылы, Кооператив ур., 20а;

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл башкарма комитетының «Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын раслау турында» 05.02.2014 елгы № 9 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, җирлекнең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kildebiak, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: ТР, Саба районы, Килдебәк, Кооператив ур., 20а; рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Заһидуллин